**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы**
**Әмәкәй авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**24 март 2025 ел** **№ 85**

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Әмәкәй авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районың Әмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 31 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Әмәкәй авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Әмәкәй авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын да кертеп, аның график сурәте белән бергә (2 нче кушымта), әлеге карар кабул ителгәннән соң 5 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (muslumovo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Әмәкәй авыл җирлегенең Әмәкәй, Иске Әлмәт авыллары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча халыкка җиткерергә:

Әмәкәй авылы, Фәррахов ур., 32 йорт (мәдәният йорты бинасы);

Иске Әлмәт ав., Ленин тыкрыгы, 3нче йорт (авыл клубы бинасы).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы: И.И.Шакирянова

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Әмәкәй авыл җирлеге Советы сессиясенең2025 елның 24 мартында үткән 85 номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының "Әмәкәй авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органына депутатлар сайлаулар буенча сайлау округлары
СХЕМАСЫ

| № п/п | Сайлау округы исеме, № | Сайлау округына кергән торак пунктлар | Сайлау округына кергән урамнар | Сайлау округына кергән йорт саннары | Сайлау чылар саны |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Әмәкәй<br>№ 1 | Әмәкәй авылы | Революция урамы | тулысынча | 44 |
| | | | Киров урамы | №№ 77 – 83<br>№ 10 | |
| | | | Ленин урамы | №№ 15 – 29<br>№№ 12 – 16 | |
| 2 | Әмәкәй<br>№ 2 | Әмәкәй авылы | Ленин урамы | №№ 1 – 3<br>№ 2 | 39 |
| | | | Киров урамы | №№ 47 – 75<br>№ 8 | |
| | | | Вахитов урамы | тулысынча | |
| 3 | Әмәкәй<br>№ 3 | Әмәкәй авылы | И.Фаррахов урамы | №№ 21 – 37<br>№№ 26 – 36 | 43 |
| | | | Ленин урамы | №№ 5 – 13<br>№№ 4 - 10 | |
| | | | Тукай урамы | тулысынча | |
| 4 | Әмәкәй<br>№ 4 | Әмәкәй авылы | Киров урамы | №№ 37-45 | 42 |
| | | | Базар урамы | тулысынча | |
| 5 | Әмәкәй<br>№ 5 | Әмәкәй авылы | И.Фаррахов урамы | №№ 11 – 19<br>№№ 10 – 24 | 45 |
| | | | Гагарин урамы | тулысынча | |
| | | | Киров урамы | №№ 21 – 35 | |
| 6 | Әмәкәй<br>№ 6 | Әмәкәй авылы | Киров урамы | №№ 1 – 19<br>№№ 2 – 6 | 40 |
| | | | Киров борылышы | полностью | |
| 7 | Әлмәт<br>№ 7 | Әмәкәй авылы | И.Фаррахов урамы | №№ 1 – 9<br>№№ 2 – 8 | 46 |
| | | Иске Әлмәт авылы | Тулысы белән | | |

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Әмәкәй авыл җирлеге Советы сессиясенең2025 елның 24 мартында үткән 85 номерлы карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Әмәкәй авыл җирлегенең бермандатлы сайлау округлары схемасының график рәсеме

